УДК 821.512.145

***Г.Р. Насибуллова***

# «КАЗАН УТЛАРЫ» ЖУРНАЛЫ
# ҺӘМ ХӘЗЕРГЕ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ

В данной статье рассматривается отражение современной татарской литературы на страницах журнала «Казан утлары». Изучаются пути и способы влияния журнала на развитие и определения основных тенденций литературы.

**Ключевые слова:** современная татарская литература, литературный журнал, «Казан утлары».

Әдәби әсәрләрне халыкка беренчеләрдән булып җиткерүдә, төрле иҗат көчләрен туплауда һәм үстерүдә, әдәбият үсешенә этәргеч бирүдә һәм аны халыкка танытуда, кешелекне тәрбияләүдә журналлар-басмалар әһәмиятле роль башкара. Дөрес, соңгы елларда яшәешебезнең зур тизләнеш алуы, төрле электрон мәгълүмат чаралары, Интернет челтәренең үсеш алуы язма әдәби басмаларның мөһимлегенә йогынты ясамыйча калмый. Әмма республикабызның төп әдәби басмасы булган, гасырга якын тарихи дәвердә үз юнәлешен, үз урынын булдырган «Казан утлары» журналының дәрәҗәсе әлеге бу үзгәреш җилләре тәэсирендә җуелмый.

«Казан утлары» журналы үзенең яшәешендә татар әдәбиятының җәүһәргә тиң әсәрләрен халыкка җиткерүче мәйдан булып кына калмыйча, тагын да камилрәк әсәрләр иҗат итүгә этәргеч вазифасын да башкара. Басмалар аша татар әдәбиятының үсеш тарихын, үзенчәлекләрен күрергә мөмкин. Журнал һәрвакыт заман белән бергә атлый. Әгәр «Казан утлары»ның барлык саннарын бергә тупласаң, татар әдәбияты тарихын тулаем күрергә мөмкин, бу үзенә күрә бер антологиягә тиң җыентыкка әверелер иде.

«Казан утлары» укучысын яңа әсәрләр белән алар китап булып басылып чыкканчы ук, беренчеләрдән булып таныштыра. Бер яктан, башлап язучы өчен журналда әсәре басылу язучы яисә шагыйрь статусы алу белән тәңгәлләштерелсә, икенче яктан, укучыга барып җитү, танылу өчен киң мәйдан ача. Журнал күпсанлы яңа әсәрләрдән иң-иңнәрен сайлап алырга тырыша. Мәсәлән, 2016 елда журналда 36 шагыйрь иҗатына урын бирелә, 4 яңа роман, 13 хикәя, 8 бәян, 1 драма, 2 поэма жанрындагы әсәрләр басыла. Бу соңгы елларда иҗат ителгән әсәрләр күләменең азлыгын билгеләми (алар бу саннардан шактыйга күбрәк), ә редакция хезмәткәрләре хезмәтенең катлаулылыгын күрсәтә.

Соңгы биш-алты елда «Казан утлары» журналында басылып чыккан әсәрләргә игътибар итсәк, проза әсәрләренең саны да, сыйфаты да үсү-үзгәрештә булуы күзгә ташлана. Басма аша хәзерге татар әдәбиятының темати-

касын билгеләргә мөмкин. Язучыларыбыз күбрәк игътибарны үткәнне тасвирлауга юнәлтә. Нигездә авылда туып-үсеп шәһәргә чыгып киткән кешенең язмышы яисә үткәнен сагынуы сурәтләнә. Мәсәлән, Ахирнең «Таш калада баш кала» (2014) романында әлеге проблема үзәктә тасвирлана. Шулай ук журналның соңгы елларында күп саннарда урын алган хикәя-бәяннар да күбесенчә үткәнне тасвирлау, үткәнне сагынуга багышланган. К. Кәримовның «Тургайлы болытлар» (2015) роман-элегиясендә дә бүгенге тормыш үткәннәр белән бәйләп тасвирлана. Бүгенге вазгыятьне, бүгенге проблемаларны чагылдыручы әсәрләр юк дәрәҗәсендә. Әдәбият галиме Т. Галиуллин да бер әңгәмәдә әлеге күренешкә борчылуын белдерә: «Язучылар арасында шундый күренеш сизелә – күбесе тарихка кереп киттеләр. Тарих – ул бер яклы трамвай. Артка чигенеп, аны тикшереп булмый. Теләсә нинди фантазия, хыял уены тарихи әсәрләргә бата. Әдәбиятны тарихи әсәрләр басты. Шуның аркасында диимме инде, хәзерге тормышыбызны чагылдырган әсәрләргә кытлык. Тарихны тикшереп булмый, анда ничек язсаң да ярый. Ә хәзерге тормышны чагылдырсаң, ул бөтен кешенең күз алдында. Алдалап язып булмый. Язучыга шуңа күрә дә хәзерге тормышыбызны чагылдыру күп тапкырлар кыенрак. Ләкин бүгенге хәлләрне без язып калдырмасак, киләчәктә хәзерге вазгыятебезне аңламаячаклар» [http://tatar-inform.tatar/news/2017/02/28/135910/]. Галим фикере әлеге күренешнең «Казан утлары» журналы кимчелеге генә түгеллеген, ә хәзерге татар әдәбиятының бүгенге халәте икәнен раслый.

Әлбәттә, «Казан утлары» журналы, республикабызның төп әдәби басмасы буларак, татар әдәбияты белән бергә атларга бурычлы. Журнал бүгенге үзгәреш-үсешләрне чагылдырып кына калмыйча, язучыларыбызга юл күрсәтергә, җитешсез якларны сиземләргә, аларны төзәтү яисә юкка чыгару өстендә эшләргә, үзгәрешләр кертергә дә сәләтле. Бу максаттан чыгып, «Казан утлары» журналы татар әдәбиятының «авырткан» урынын сизеп алырга һәм аңа ярдәм итәргә омтыла. Әдәбиятны төрле жанрлар ягыннан баету өлкәсендәге эшчәнлеге моңа дәлил. Әдәбиятны җанландыру, төрлеләндерү максатыннан журнал төрле конкурслар оештыра. Мәсәлән, «Иң яхшы хикәя», «Хикәя яза аласызмы?», «Иң яхшы чәчмә әсәр», «Яңа дәвер кешесе» кебек конкурслар хикәя жанры үсешенә йогынты ясамый калмады, хәтта әлеге өлкәдә эшләүчеләрнең күплеген һәм төрлелеген ачыкларга да ярдәм итте. Моннан берничә ел элек журнал иң яхшы повесть жанрындагы әсәрләргә конкурс игълан иткән иде, ул татар әдәбиятында сүлпәнләнеп баручы әлеге төр әсәргә уңай тәэсир ясады, язучыларыбызны дәртләндереп җибәрде. Әлеге конкурс аша авторларны эзләнүләргә этәргән яңа әсәрләр, яңа алымнар, яңа сюжетлар белән таныштык. Мәсәлән, бәйгегә килгән повестьлар арасында З. Хәкимнең бүгенге дөньяның саркастик

моделен чагылдырган «Сәер никрут», Р. Зариповның тормыш дөреслеген тасвирлаган «Милициянең йөз аклыгы» бәяннары игътибарга лаек. Әлеге конкурс-бәйгеләрнең әдәбият үсеше өчен тагын бер әһәмияте – яңа исемнәрне әдәби мәйданга чыгару.

«Казан утлары» журналы яңа исемнәрне, башлап язучыларны конкурс-бәйгеләр аша гына түгел, ә аларга аерым рубрикалар багышлап та эзләп табарга, әдәби мәйданга күтәрергә омтыла. Журнал басылып чыга башлаган көненнән үк әдәбият өлкәсенә аяк басучылар өчен үзенә күрә «әдәби капка» ролен башкарган. Татар әдәбияты тарихында урын алган олпат язучыларыбыз да заманында аның аша әдәби мәйданга үткән, танылу алган. Дөрес, бүгенге көндә әдәби басмалар шактый, вакытлы матбугат та әдәби әсәрләргә киң урын бирә, Интернет челтәре аша да укучы аларны табып укый ала. Әмма «Казан утлары» журналының рәсми булмаган «әдәби иләк» вазифасын үтәүче дәрәҗәле исеме актуальлеген югалтмый. Мәсәлән, соңгы елларда барлыкка килгән «Яңа исемнәр» рубрикасы әдәбият дөньясында билгеле булмаган яңа иҗатчыларны мәйданга чыгарды. Журналның 2016 елгы саннары аша без Эльвира Сафина, Лилия Фәттахова, Айсылу Хафизова кебек каләм тибрәтүчеләр белән танышабыз.

Соңгы елларда яңа бәйгеләр, рубрикалар белән беррәттән юкка чыккан, журнал битләреннән төшеп калган сәхифәләр дә бар. Мәсәлән, «Китапка күзәтү» рубрикасы соңгы еллар саннарында пассивлашты. Әлеге сәхифә яңа басылып чыккан китапларга күзәтү ясап, язучының хезмәтенә беренче бәясен биреп, укучыны яңалык белән таныштырып, аны укырга этәрүдә әһәмиятле роль башкара иде. Әлеге традиция дәвам иттерелсә яисә журнал битендә аерым әсәр хакында сөйләшүләр оештырылса, аңа анализ бирелсә, бу юнәлеш башлап язучылар өчен үзенә күрә бер дәрес, заманчалаштырып әйтсәк, мастер-класс булыр, татар әдәбиятын пропагандалауда, укучыны әдәби әсәрләр укырга этәрүдә мөһим роль уйнар иде.

«Казан утлары» журналы хәзерге әдәбият белән таныштырып кына калмыйча, бүгенге үзгәрешләргә укучысының бәясен, фикерен дә белергә омтыла, шулай ук әдәбият галимнәренең уйланулары, бәяләмәләре белән таныштырып бара. Мәсәлән, 2004–2005 елларда «Безнең заман герое кем ул?» дигән сорау куеп, әдәбият галимнәрен, тәнкыйтьчеләрне, язучы-шагыйрьләрне, укучыларын уйланырга, бәхәсләшергә этәрде. Соңгы елларда әлеге фикер алышулар төрле темаларга багышланган түгәрәк өстәл формасын да алды. Шулай ук журнал 2001 елда «XXI гасыр бусагасында. Әдәбиятыбыз кая бара?» дигән сорау куеп, галимнәрне, әдәбият белгечләрен уйланырга мәҗбүр иткән иде. Журналның берьеллык басмаларына бәя бирүгә багышланган, традициягә әверелеп бара торган «түгәрәк өстәлләр» укучыларга әдәбият галимнәре, тәнкыйтьчеләр фикерләрен җиткерү белән беррәттән язучыларга үз әсәрләренә

бәя ишетү, юнәлеш-алым сайлауда да зур роль башкара.

Соңгы елларда басылган саннарны күзәтсәк, мөхәррирләрнең язучы-авторларны төрлеләндерергә тырышуын күрербез. Дөрес, араларында бик еш яңгыраучы исемнәр дә бар. Мәсәлән, Айгөл Әхмәтгалиева, Әмирҗан Моталлапов. Әлеге күренеш бу язучыларның актив иҗат итүе белән беррәттән югары әдәби кимәлдә әсәрләр иҗат итүгә сәләтле икәнлеген дә аңлатадыр. Әмирҗан Моталлаповны мин, гомумән, «Казан утлары» журналының табышы дип атар идем. Бу язучы соңгы елларда укучыларны матур тел белән, кеше психологиясен һәм тормышны, милли үзенчәлекләрне тоеп язган әсәрләре белән сөендерде. Аның «Гамь», «Йөзә торган арба» әсәрләре әдәбият тарихында үз урынын алырга лаеклы.

Бүгенге көндә татар әдәбиятын башка халыкларга җиткерү шулай ук иң авыр мәсьәләләребезнең берсе булып кала бирә. Дөрес, рус теленә, соңгы елларда төрек теленә тәрҗемәләр башкарылуы сөендерә, ләкин Европа телләренә тәрҗемә бөтенләй юк дәрәҗәсендә. Әйтик, классик әдәбиятыбызны инглиз теленә тәрҗемә итә алсак, ул мирас чит ил вәкилләре арасында үз укучысын тапмый калмас иде. Ә бит «Казан утлары» журналы башка халыкларның әдәби мирасын, тәҗрибәсен татар укучысына җиткерүдә зур роль башкарып килә. Соңгы елларда А. Егинның «Үзбәк хан» әсәре тәрҗемә ителеп, басма битләрендә урын алуы, казакъ язучылары әсәрләре белән танышу әнә шундый матур мисаллардан.

«Казан утлары» журналы бүгенге әдәбиятта барган үзгәрешләр хакында галим-әдәбиятчыларның фикерләре белән таныштыруга гына урын биреп калмый, ә басма саннарында урын алган әсәрләргә карата укучысының фикеренә дә зур игътибар бирә. Журналның «Кайтаваз» сәхифәсе әнә шул мөһим функцияне башкара. Биредә укучыларның уйланулары, төрле теләк-тәкъдимнәре, журнал эшчәнлегенә бәясе урын ала. Үзенә күрә журнал белән укучы арасында күпер формалаштырган әлеге сәхифә әдәбиятыбызның яшәеше-үсешенә үз өлешен кертә. Мәсәлән, соңгы саннарда без журналда күтәрелгән мәсьәләләргә карата Руфина Фаттахованың «кайтавазын» ишеттек. Әгәр язма укучыны битараф калдырмыйча, аны үз фикерен җиткерергә этәрә икән, бу инде журналның эшчәнлегенең дәрәҗәсен дә билгели.

«Казан утлары» журналы бөтен тарихы буена тел, милләт, аның яшәеше һәм үсеше сагында торды. Әдәби басма бүген дә әлеге әһәмиятле һәм катлаулы миссиясен дәвам итә.

**Чыганаклар**

1. http://tatar-inform.tatar/news/2017/02/28/135910/
2. http://kazanutlary.ru/

***Насибуллова Гүзәл Ришат кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан (Идел буе) федераль университеты доценты*